## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеген Бактачы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“14” ноябрь 2022 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №109 карары нигезендә, 2022 елның 14 ноябрендә «Сез 2023 елда Күлле-Киме авыл җирлеге Бактачы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш, 3500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бахтаче авылына юлны төзекләндерү, вак таш сатып алу һәм җәю
- дамба өчен торба сатып алу
- зират коймасы өчен төзелеш материаллары сатып алу
- чишмәне ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу
- Бахтаче авылы территориясен кардан чистарту
- урам утларына хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 31 (утыз бер) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 20 (егерме) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 20 (егерме) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Бактачы авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2023 елда Күлле-Киме авыл җирлеге Бактачы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан

тыш, 3500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- Бахтаче авылына юлны төзекләндерү, вак таш сатып алу һәм җәю
- дамба өчен торба сатып алу
- зират коймасы өчен төзелеш материаллары сатып алу
- чишмәне ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу
- Бахтаче авылы территориясен кардан чистарту
- урам утларына хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу мәсьәләсен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Бактачы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Бактачы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы Гәрәев Х.Х.